ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12 07 2021 г. № 210

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге буенча
2021 елның III кварталына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясен раслау турында

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 маендагы 322 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган яшь гаиләләр өчен күрсәтелгән түләүләр федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннары алу (төзү) өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2021 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм 2021 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2021 елның 7 июнендәге 358/пр номерлы боерыгына таянып, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елның III кварталына Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясен 58 654 (илле сигез мең алты йөз илле дүрт) сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
торак сәясәте бүлеге җитәкчесе Е.С.Митрошенкова

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881